РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.08.2017 №166-п

*Район төзелеш оешмалары коллективларының 2016 елгы эш нәтиҗәләре турында*

Район төзелеш оешмалары коллективларының 2016 елгы эш нәтиҗәләрен караганнан соң,

КАРАР БИРӘМ:

1. 189 млн. 607 мең сум күләмендә төзелеш һәм социаль объектларда ремонт эшләре алып барган, рентабельле эшләүне тәэмин иткән "159 нчы күчмә механикалаштырылган колонна" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (җитәкчесе Нәбиуллин Ф.Ә) беренче урын бирергә һәм коллективны беренче дәрәҗәдәге Диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчегә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 10 мең сум күләмендә премия бүләргә.

2. 125 млн. 868 мең сум мелиорация һәм төзелеш эшләре башкарган, рентабельле эшләүне тәэмин иткән Саба "Мелиорация" күчмә механикалаштырылган колоннасы" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (җитәкчесе Талипов И.И.) икенче урын бирергә һәм коллективны икенче дәрәҗәдәге Диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчегә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 8 мең сум күләмендә премия бүләргә.

3. 103 млн. 815 мең сум күләмендә төзү-ремонтлау эшләре башкарган, рентабельле эшләүне тәэмин иткән "Инвестхолдингстрой" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (җитәкчесе Гыйльманов Р.А.),

96 млн. сум күләмендә эш башкарып, электр энергиясен кулланучыларга сыйфатлы һәм өзлексез җиткергән "Челтәр компаниясе" ачык акционерлык җәмгыяте "Алабуга электр челтәрләре" филиалының Саба район электр челтәренә (җитәкчесе Талипов И.И.) өченче урын бирергә һәм коллективларны өченче дәрәҗәдәге Диплом белән бүләкләргә.

Җитәкчеләргә акчалата бүләк тапшырырга һәм аеруча яхшы эшләүчеләрне бүләкләү өчен 6шар мең сум күләмендә премия бүләргә.

Р.Н. Минниханов